**1нче САНЛЫ ГРАЖДАННАР ҖЫЕНЫ КАРАРЫ**

01 декабрь 2022 ел

Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Ямаширмэ авыл җирлеге Ямаширмэ торак пунктында гражданнар җыены нәтиҗәләре турында

“Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында”, 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьялары, “Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында”, 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы законының 35 статьясы нигезендә, 2022 елның 30 ноябрендә 11 сәгать 00 минутта, 2022 елның 30 ноябрендә 14 сәгать 00 минутта, 2022 елның 30 декабрендә 16 сәгать 00 минутта уздырылган “Сез 2023 елда Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Ямаширмэ авыл җирлеге Ямаширмэ авылы территориясендә даими яшәүче һәм яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән 500 (биш йөз) сум күләмендә үзара салым кертүгә һәм җыелган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияткә ия мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлдерү белән килешәсезме?” дигән мәсьәлә буенча этаплап гражданнар җыены нәтиҗәләре буенча беркетмә төзелде:

1) Ямаширмә авылында ял паркын төзекләндерү (балалар мәйданчыгы, урам тренажерлары сатып алу);

2) Ямаширмә авылы эчендәге юлларны ремонтлау һәм карап тоту (таш сатып алу, юлларны кышкы карап тоту: трактор өчен ягулык-майлау материаллары сатып алу);

3) трактор җиһазларын сатып алу;

4) Ямаширмә авылының су башнясына проект-смета документациясе .

«РИЗА» «КАРШЫ».

Гражданнар җыены нәтиҗәләре турында беркетмә нигезендә:

Сайлау хокукына ия җыенда катнашучылар исемлегенә гражданнар җыенында катнашучы 810 (сигез йөз ун) кеше кертелгән, тавыш бирүдә катнашкан гражданнар саны 420 (дурт йөз егерме) кеше, бу 52%ны тәшкил итә.

тавыш бирү нәтиҗәләре буенча гражданнар җыенында катнашучылар түбәндәгечә бүленде:

“Риза” позициясе өчен гражданнар җыенында 420 (дурт йөз егерме) катнашучы тавыш бирде; “Каршы” позициясе өчен җыенда катнашучы 0 (ноль) кеше тавыш бирде.

Бәян ителгәннәрдән чыгып, гражданнар җыены түбәндәгечә хәл итте:

1. Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Ямаширмэ авыл җирлеге Ямаширмэ торак пунктында гражданнар җыенын узган дип, гражданнар җыены нәтиҗәләрен дөрес дип танырга.

2. 2023 елда үзара салым акчасын яшәү урыны буенча теркәлгән һәм

Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Ямаширмә авыл җирлеге территориясендә даими яшәүче балигъ булган һәр кешедән 500 сум (биш йөз) күләмендә кертергә.

3. Алынган акчаларны җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә түбәндәге эшләрне башкару өчен җибәрергә:

1) Ямаширмә авылында ял паркын төзекләндерү (балалар мәйданчыгы, урам тренажерлары сатып алу);

2) Ямаширмә авылы эчендәге юлларны ремонтлау һәм карап тоту (таш сатып алу, юлларны кышкы карап тоту: трактор өчен ягулык-майлау материаллары сатып алу);

3) трактор җиһазларын сатып алу;

4) Ямаширмә авылының су башнясына проект-смета документациясе .

4. Аерым мәсьәләләр буенча экономияләнгән очракта Ямаширмә авыл җирлеге башкарма комитетына җыен белән билгеләнгән башка мәсьәләләрне хәл итүгә акча җибәрергә рөхсәт итәргә кирәк.

5. Россия Федерациясе Президентының «Россия Федерациясендә өлешчә мобилизацияләүне игълан итү турында» 2022 елның 21 сентябрендәге 647 номерлы Указы нигезендә Россия Федерациясе Кораллы Көчләренә мобилизация буенча хәрби хезмәткә чакырылган Россия Федерациясе гражданнарын, тыл хезмәтчәннәрен һәм 1 төркем инвалидларны (исемлек бирелә) 2023 елда үзара салым түләүдән тулысынча азат итәргә.

6.Әлеге карарны Биектау муниципаль районы рәсми сайтында Интернет челтәрендә http://vysokaya-gora.tatarstan.ru веб-адресы һәм Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында “Интернет” мәгълүмат-телекоммуникацияләр челтәрендә http://pravo.tatarstan.ru бастырып чыгарырга (халыкка җиткерергә).

7. Әлеге карарны Татарстан Республикасы муниципаль норматив хокукый актлар регистрына кертү өчен җибәрергә.

Гражданнар җыенында рәислек итүче Ф.К.Мухтаров